Чыганак: Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская: әдәби нәфис, документаль, биографик җыентык / авт.-төз. Җ. Миңнуллин (фәнни мөх.); редкол.: И. Г. Әхмәтҗанов, Р. И. Вәлиев, Ф. М. Рәфыйков. – Казань: Җыен, 2012. – 479 б.: фоторәс. б-н. – (Шәхесләребез). – Библиогр.: б.465-474.

Сәхибҗамал Гыйззәтуллинаның Казан тамашачысы каршында беренче чыгышлары булса да, халыкның игътибарын тәмам үзенә җәлеп итеп, зур алкышлар алганын хәтерлим. Тиздән Галиәсгар Камалның тәкъдиме буенча мин театрга эшкә кердем. Кариев миңа суфлерлык вазифасын тәкъдим итте.

1912–1913 еллар. «Сәйяр» труппасы белән гастрольгә китkән җирдән каты авырып Троицк шәһәр больницасына кереп калдым. Бер вакыт миңа Оренбургтан хат килде. Ул хат Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның мине үз труппасына чакырып язган хаты иде. Больницадан чыгу белән Оренбургка киттем. Сәхибҗамал Гыйззәтуллина мине ачык йөз белән каршы алды. Аларның кайбер артистлары солдаткa каралу сәбәпле кешеләре җитми икән. Труппаның репертуарында «Җиңел хезмәттә», «Хөкемдә хаталык», С.Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» һ. б. әсәрләр бар иде.

Сәхибҗамал апа: «Мәкер вә мәхәббәт»не куярга бик ашкынып йөрсәм дә, ирләр составы аз булганлыктан куя алмыйм. Әсәрдәге Луиза ролен уйнау теләге миндә Казанда чакта ук туган иде инде. Ләкин уйнарга насыйп түгел әле», – диде.

1914–1915 еллар сезонын йомгаклаганда Оренбургта чыга торган «Вакыт» газетасында Кәбир Бәкернең безнең спектакльләрне шактый мактаган мәкаләсе чыкканы хәтердә. Аннары Уфада бераз уйнаганнан соң Чиләбегә киттек. Әмма ураза ае кергәнлектән, без анда спектакль куя алмадык. Артистлар вакытлыча кайсы кая таралдылар. Сәхибҗамал Гыйззәтуллина театрны бик якын күргән таныш Гариф Борнаевларда ял итәргә булды. Шәһәрдә моңа кадәр ак билет белән сугыштан калып торган кешеләргә мобилизация булу хәбәре таралды. Мин дә шундыйларның берсе булганлыктан, Борнаевның: «Син хәзер утыр да Кытай чигенә – Нурзайсанга кит, анда әле ак билетләрне тиз генә алмыйлар», – дигән киңәшен тотып, Нурзайсанга чыгып киттем.



Ләкин барыбер котыла алмадым. Омск шәһәрендә мине солдатка алдылар. Шәһәрдән читтә, бер солдат казармасында һичбер кешедән хәбәр ала алмый яттым. Тик кулымдагы «Вакыт» газетасыннан Кәбир Бәкернең мәкаләсен кат-кат укып кына хөрмәтле «Туташ»ны искә ала торган идем. Без, артистлар, үз арабызда аны бик яратып һәм хөрмәт итеп «Туташ» дип кенә атый идек.

*(Истәлек беренче мәртәбә «С. Гыйззәтуллина-Волжская турында истәлекләр». / Төз. Х.Гобәйдуллин.– Казан, 1982, (Б. 33–36) китабында бастырылган. Текст шуннан алынды.)*

***Риза Ишморат***[1]

## Рәхмәтем зур аңа

Театр кешеләр рухын бөеклеккә күтәрә, тетрәндерә, шатландыра, нурландыра, аңа бәхет бүләк итә торган иң көчле, тылсымлы сәнгать.

Илле елдан артык гомерем театрга багышланган. Хәтер йомгагын сүтеп, театр юлындагы беренче адымнарымны күздән кичерәм, уйланам...

Ниндидер көчләр, кемнәрдер мине җилкендереп, әйдәп, театр юлы белән алып киттеләр. Кемнәр алар? Кайдан башланды бу? Хәтерләргә тырышам: менә миңа 14–16 яшьләр. Мин – шәкерт. Уфада Госмания мәдрәсәсендә укыйм. Әдәби кичәләрдә яттан шигырьләр сөйлим. Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев һәм башкаларның шигырьләрен. Тукайның «Суык» дигән шигыреннән өзек – «Кичә генәк» – минем даими репертуарым. Тамашачылар яратып, алкышлар белән кабул итәләр. С.Рәмиевнең «Кеше» исемле шигырен дә яратып тыңлыйлар, кул чабалар.

---

[1] *Риза Ишморат (1903–1995)* – күренекле татар язучысы, драматург, ТАССР һәм РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Залдагы кешеләрнең көлүләре, йотлыгып тыңлаулары синең күңелеңдә бер ашкыну хисе тудыра, рәхәтлек, ләззәт бирә. Сәхнә белән тамашачы арасында гаҗәеп бер бәйләнеш, сихри бәйләнеш бар. Сәхнәдән сөйләүче декламаторны, артистны шул тарта сәхнәгә, тамашачыны да шул көч тартып кертә тамаша залына. Әнә шул көчнең асыл серенә төшенер-төшенмәс йөргән нәкъ менә шундый көннәрнең берсендә миңа «Нур» труппасының «Хөкемдә хаталык» исемле спектаклен күрү насыйп булды.

Урам буйлап барганда кызыклы бер афишага күзем төште. «Новый клуб» бинасында «Нур» труппасы татарча спектакль куячак,– диелгән. Пьесаның авторлары французлар: Д.Эннери һәм Кармен. Тәрҗемәчесе – Галиәсгар Камал. Спектакльдә катнашалар: Жан Рено ролендә – Гыйлаҗ Казанский, Адриенна – Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Магдалина – Зөләйха Богданова, Шамбурен – Зәки Баязитский һ.б. Әсәрне сәхнәгә куя – Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская.

Гомеремдә беренче тапкыр спектакль каравым иде бу. Театрның нәрсә икәнен чамалыйм. Пьесалар да укыганым бар. Сараш авылында Сәгыйть абый Сүнчәләйләрдә укыган чакта классташ дустым Мулланур Гайсиннарның бик җыйнак кына мунчаларында «Каенана өйдә булса өйнең асты өскә килә» дигән пьесаны кычкырып укый идек. Һәм уйнаган булып кылана идек. Шуның өстенә Генрих Гейненең Сәгыйть Сүнчәләй тәрҗемә иткән «Әлмансур» трагедиясен үз-үземә кычкырып укып, «уйнап» чыга идем. Ләкин бит ул «театр» үзем өчен, үзебез өчен генә. Ә монда – чын театр. «Нур» исемен йөрткән, халык күңелен яктырту нияте белән оешкан профессиональ театр. Башка артист яисә артисткаларны ишеткәнем, күргәнем юк. Ә менә Сәхибҗамал Гыйззәтуллина исемен ишеткәнем бар. Ул – атаклы кеше. Аның турында Г.Тукайның язган шигырен дә хәтерлим.



Театрга кердем. Халык шыгрым тулы. Яхшы гына, ыспай гына костюм, казаки кигән ирләр. Байтагы галстуктан. Ак күлмәк, ак яка. Күбесенең башында яхшы кәләпүш-түбәтәй. Уфа зыялылары, приказчиклар, хәлфәләр, шәкертләр, гимназистлар, дарелмөгаллиматта укучы кызлар. Гади генә киемлеләре дә аз түгел. Яшел йә кара гимнастерка һәм шул заманга хас булган галифе чалбар, аякларына итек киеп, билләренә наган таккан иптәшләр дә юк түгел. Хатын-кызлар да күп, калфаклылар да, чәч толымнарын матур итеп үреп, бантик кадап куйган чибәр-чибәр туташлар да бар. Кайберәүләре башларына кызыл, алсу косынка бәйләп куйган. Елның авырлыгына да карамастан (1918 ел) халык бер бәйрәмгә җыелган кебек тоела.

Зал зур түземсезлек белән спектакль башлануын көтә. Звонок булыр-булмас ук үз урыныма кереп утырдым. Менә шау-гөр килеп тамашачылар залга тулды һәм пәрдә дә ачылды. Сәхнә белән тамаша залын аерып торган пәрдә... Гаҗәп! Ефәкме ул, бәрхетме, йә булмаса гади киндер генәме, нинди генә булмасын, барыбер могҗизалы хасияте бар бу пәрдәнең. Аның артында тамашачы өчен бөтенләй серле бер дөнья...

«Хөкемдә хаталык» драмасының фаҗигале вакыйгаларга корылган булуын ишетеп калган идем. Чыннан да, дөрес икән.

Биш-алты яшьлек кыз бала, үз анасын кем үтерүе хакында берни белмәгән килеш, үтерүченең мәкерле хәйләсенә алданып, үз атасын гаепле итеп күрсәтә. Атаны мәңгелек каторгага хөкем итәләр. Бала үсә. Унҗиде-унсигез яшьләр тирәсенә җиткәч, кул-аяклары богауланган, ябыгып эштән чыккан, сакал-мыек баскан атасы белән очраша.

Башта танымый ул аны, соңрак таный һәм...

Кыз ролендә – Сәхибҗамал Гыйззәтуллина, каторжан ата ролендә – Гыйлаҗ Казанский... Йә хода! Булса да булыр икән шундый мәрхәмәтсез язмыш,

шундый уен... Юк, уен түгел бу... Бу чын тормыш. Бу француз кызы Адриенна үзе. Әнә бит ул ничек өзгәләнеп атасы белән сөйләшә. Аның күз карашлары, сөйләгән сүзләре, һәрбер хәрәкәте тетрәтә, йөрәкне өзгәли... Шулай да аңлыйм: бу – театр. Сәхнәдә – Адриенна булып киенгән артистка Сәхибҗамал Гыйззәтуллина. Шундый табигыйлек, нәзакәтлелек, шундый мөлаем һәм музыкаль тавыш... Ә нинди көч аңарда! Ата тиешле кешенең хәрәкәтләре, йөреш-торыш, күз карашлары да шундый табигый, нәкъ тормыштагыча... Юк, аларның уены тормыштагыга караганда да табигыйрәк, күп көчлерәк... Менә ни өчен нурлы кояшка тиңләп әйткән икән Сәхибҗамал турында Габдулла Тукай.

Спектакль миндә шундый көчле тәәсир калдырды ки, мин атналар буе шуның тәэсирендә яшәдем. Көндезен дә, кичен дә Адриенна – Сәхибҗамалның җәзебәле[1] күз карашлары минем күз алдымда торды, музыкаль аһәңле, ярсулы тавышы колак төбемдә яңгырады. Атасы сурәте дә, аның җан тетрәткеч кыяфәте дә күз алдымнан китмәде. Атналар гынамы – еллар, гомерем буе... Әле булса колонналы таш баскыч янында ата белән кызның очрашуы күз алдымда тора...

Халкыбызның гайрәтле, тирән хисләргә бай һәм мәгърур талант иясе, тыйнак та, әдәпле дә кызы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская төзегән «Нур» труппасы спектакле әнә шулай сихерле дә иде. Беренче спектакль мине икенчесенә тартты, икенчесе өченчесенә... Ашарга-эчәргә дигән акчаларыма, театр билеты сатып алып, спектакльләргә йөри башладым.

Ә беркөнне мин кармакка каптым. Ишек төбендә атаклы артист Шакир Шамильский үзе тора иде. Билет тикшерүчегә ярдәм итә иде. Минем кебек «куяннар» тотаргадыр инде, мөгаен.

[1] *Җәзеб* – үзенә тарту.



– Әй, шәкерт, кая, күрсәт әле билетыңны!
– Менә, абый.
– Нигә моның контроле юк?
– Алганда ук ертык иде ул.
– Алдашма! Андый билет сатмыйлар бездә. Кайсы мәдрәсәдә укыйсың?
– Госманиядә, Шакир абый.

Әллә минем Шакир абый дип исем белән әйтү ошады моңа, әллә мескенрәк кыяфәтемә карап кызганды мине, артык төпчеп тә, ачуланып та тормады. «Бар, тик икенче алай алдашма!» – дип залга уздырып җибәрде. Менә бит нинди рәхмәтле бәндә икән Шакир абый, дип уйлап куйдым сөенә-сөенә тамаша залына узып.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китим. Бу хәлгә унбиш ел вакыт узгач, мин Татар дәүләт академия театрында баш режиссёр булып эшләгән чакта, исенә төшердем Шакир абыйның бу эшен.

– Театрга куян булып кергән чагымда син мине бер тотып алып кызарткан идең, – дим.
– Ну?.. Булмас ла!.– диде бу көлеп.
– Ләкин рәхмәт сиңа, җилкәләп кире чыгармадың. Залга спектакль карарга кертеп җибәрдең, – дим.
– Менә бит ничек ул, Риза туган, димәк, син безнең үз кешебез булачагыңны мин шул вакытта ук чамала-ганмын.
– Шулай булып чыга, – дип рәхәтләнеп көлештек аның белән.

Шулай итеп, мин «Нур» труппасында куелган күп спектакльләрне карадым. Игътибарым үзәгендә һәрвакыт Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская һәм ул иҗат иткән образлар булды. Гыйлаҗ Казанский белән Шакир Шамильский да иң яраткан артистларым иде. Театр сәнгатенең атаклы осталары, олы хөрмәткә лаеклы изге йөрәкле кешеләр иде алар безнең өчен.

Г.Камалның «Бәхетсез егет» драмасы буенча куелган спектакльне миндә аеруча көчле тәэсир калдырды. Бәхетсез егет ролендә Шакир Шамильский уйнады. Аңардагы гаҗәеп бер табигыйлек, тормышчанлык, самимилек һәм йөрәкне тетрәтерлек эчке драматизм... Аның башкаруында Закир чын мәгънәсендә революциягә кадәрге каһәрле тормышның корбаны булып күз алдына килеп баса иде. Ә Гайни? Сәхибҗамал Гыйззәтуллина башкара торган Гайни... Сәхнә ачылуга, тамашачы алдына затлы материалдан килешле итеп, мода белән тегелгән озын күлмәк, башына энҗеле калфак кигән, муенына кыйммәтле энҗе муенса таккан мөлаем йөзле, гаҗәеп бер мәһабәт хатын килеп баса. Аның гүзәллеген күреп сокланасың, ә бераздан Закирга, гомумән, ирләргә мөгамәләсен, гадәт-холкын белгәч, шундый нәфис, мөлаем йөзле кызның коточкыч бозык, комсыз, мәкер иясе булуын күреп, хәйран каласың. Бер караганда, гаҗәеп бер самими нәзакәтлелек, күз сирпеп елмаюлар, кычкырып көлүләр, икенче карасаң, күзләрендә, елмаюында, барлык хәрәкәтләрендә хәйлә, мәкер... Боргалана, сыргалана, зәһәрләнеп авызыннан утлар чәчә, тамашачы алдында берсеннән-берсе әшәке, җирәнгеч сыйфатлары белән ачыла бара. Ниһаять, синең күз алдыңа тупас, надан, тәмам эштән чыккан бер бозык хатын килеп баса. Ихтыярсыздан син чирканасың, нәфрәтләнәсең. Гайнинең: «Мин синең кебек жуликларны күп күргән, сине хәзер үк этап белән төрмәгә озатам», – дигәне Закирны чыгырыннан чыгара һәм ул аңа револьвердан ата. Гайни бары «Аһ!» дип әйтергә генә өлгерә. Егыла. Үлә. Бу фаҗигале үлемне Сәхибҗамал ханымның искиткеч зур осталык белән башкаруын күреп син нык дулкынланасың... Шуның артыннан ук икенче фаҗига: Закир үзен үзе атып үтерә. Нишләргә белми куркып, аптырап калган чагында пәрдә төшә. Пәрдә... Мин кинәт уянып киткәндәй аңыма киләм. Ярый



әле, Аллага шөкер, бу хәл бары театрда гына икән, дип сөенеп, тамашачыларга кушылып, кул чаба башлыйм. Менә бит – тагы бер могҗиза. Чынбарлык түгел бу – сәхнә, Закир да Закир түгел – артист Шамильский, Гайни дә Гайни түгел – артистка Сәхибҗамал Гыйззәтуллина. Гайни... Шулкадәр зур осталык белән иҗат ителгән образ... Юк, тормыштагы чын Гайниләр дә болай оста кылана белмиләрдер. Аларга мондый осталыкка театрдан, Сәхибҗамал Волжскаядан өйрәнергә кирәк. Менә нинди кодрәтле көчкә ия бит талант иясе Сәхибҗамал апа.

Беркөнне шулай «Нур» труппасы, артистка Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская турында сүз чыккач, Шәриф абый Сүнчәләй Гыйззәтуллинаның яхшы артистка гына булмыйча, шушы «Нур» труппасын оештыручы да һәм артистларны сәхнәдә уйнарга өйрәтүче режиссёр да булуын сөйләде. Әнә ничек икән ул: артистларны сәхнәдә уйнарга өйрәтә, кыланырга гына түгел, ә икенче кеше – образ булып яшәргә өйрәтә... Мин бу гали затны сәхнәдән генә түгел, тормышта күрәсем, аңа берничә генә булса да сүз әйтәсем килде. Әмма Уфада яшәгән чорда аны кайчак урамда йә театрда очратканым булса да, туктатып, яисә янына барып сүз кушарга, рәхмәт белдерергә батырлыгым җитмәде.

Бу рәхмәтне мин бары тик кырык тугыз елдан соң, Октябрьның 50 еллык бәйрәме көннәрендә генә әйтә алдым.

Сәхибҗамал ханым Казанда яши иде. Ул инде озын тормыш юлы үткән кеше. Гражданнар сугышы елларында атаклы Азин дивизиясендәге татар труппасы, Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясе политотделы каршындагы труппада эшләгән, Кызыл гаскәрләргә культура хезмәте күрсәтеп, авыр һәм куркыныч шартларда дәүләтебезне дошманнан саклап калуда ярдәм иткән кеше. Җыелыш залында Сәхибҗамал ханым Совет дәүләтенә, партиябезгә кайнар рәхмәтен белдереп, речь сөйләде. Мин аның

бу чыгышын да нәкъ теге вакытларда беренче спектакльләрне карагандагы кебек бирелеп, дулкынланып тыңладым. Һәм аның янына килеп:

– Рәхмәт сезгә, Сәхибҗамал ханым, сез барыбыз исеменнән бик мәгънәле һәм кайнар итеп сөйләдегез, – дип аның кулын кыстым. Ул миңа таныртанымас кына карап куйгач:

– Оныткансыздыр, бәлки, без Татар дәүләт академия театрында бик кыска гына вакыт арасында күрешеп танышкан идек, – дидем. «Таныйм, таныйм, сез бит фәлән-фәлән кеше», – дип, Сәхибҗамал ханым исем-фамилиям һәм элек театрда эшләгән кеше икәнемне дә әйткәч, мин аңа:

– Сәхибҗамал ханым, минем әле илле елга якын Сезгә әйтә алмый йөргән аерым зур рәхмәтем бар, – дидем.

– Нинди рәк рәхмәт икән ул?

Сәхибҗамал ханым үзенең күңелгә үтеп керә торган тылсымлы, ләкин инде еллар моңсулыгы баскан күзләре белән миңа карады.

– Минем бит театр өлкәсенә кереп китүгә төп сәбәпче кеше сез булдыгыз.

– Мин?!

– Әйе. Сез... Сез уйнаган рольләр – «Хөкемдә хаталык» мелодрамасында Адриенна, «Бәхетсез егет»тәге Гайни һәм башка пьесаларда сез тудырган образлар. Шулай ук «Нур» труппасындагы артистларыгыз Гыйлаҗ Казанский, Шакир Шамильский һәм башкалар... Сез төзегән «Нур» труппасы тәмам сихерләде мине һәм театр юлына кереп китүемә иң зур сәбәпче булды. Иҗатым яхшымы, яманмы, ләкин моның өчен мин башлыча Сезгә, «Нур» труппасына бурычлымын. Шуңа күрә Сезгә барысы өчен дә кайнар һәм иң самими рәхмәтемне белдерәсем килә...

Ул тагын миңа бер елмаеп карап: – Рәхмәт! – диде.



Театрыбыз сәнгатенә нигез ташы салучыларның берсе, атаклы артистка белән булган бу сөйләшү күңелдә тирән уелып калды.

Сүземне очлап шуны әйтәсем килә: утызынчы елларда миңа «Нур» труппасы артистлары Шакир Шамильский, Гыйлаҗ Казанский, Локман Аитовлар белән Сәхибҗамал Гыйззәтуллина турында күп кенә мәртәбәләр сөйләшергә туры килде. Алар барысы да Сәхибҗамал ханымны аеруча бер җылылык, зур хөрмәт белән искә алалар иде.

«Сәхибҗамал ханым (без аны барыбыз да «туташ» дип йөртә идек) – бик талантлы, югары культуралы артистка, режиссёр һәм педагог. Аның сүзе барыбыз өчен дә закон булды. Театрны үстерү өчен барлык авырлыкларны да күтәрергә риза булган гаять тырыш, гадел һәм олы йөрәкле кеше иде». Гаделлек, тыйнаклык һәм олы күңеллелек үрнәге булган Шакир Шамильский Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская турында әнә шулай ди торган иде.

*(Истәлек беренче мәртәбә «С. Гыйззәтуллина-Волжская турында истәлекләр». /Төз. Х.Гобәйдуллин.– Казан, 1982, (Б. 54–60) китабында басылган. Текст шуннан алынды.)*

***Мәрьям Зәйнуллина***

## Сөекле актрисам

Беренче рус революциясеннән соңгы еллар иде. Мин үзебезнең туган авылыбыз Бубый мәктәбенә укырга кердем. Ул чорда ук инде беренче татар артистлары Г.Кариев, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның фотооткрыткаларын күп татар гаиләләре альбомнарында очратып була иде. Укымышлы кешеләр алар белән горурлана, чын күңелдән ихтирам итә иде. Безнең кызлар мәктәбендә спектакльләр